**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 июнь № 445

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында » 2010 ел, 02 сентябрь, 699 нчы карарына теркәлгән кушымтага үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында » 2010 ел, 02 сентябрь, 699 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 16 март, 192 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) теркәлгән кушымтага, түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәп, үзгәреш кертергә:

«Искәрмә. Хуҗалары (подрядчылары, үтәүчеләре, тәэмин итүчеләре) Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма корылмаларны төзү, төзекләндерү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту буенча дәүләт контрактлары төзегән (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) транспорт чаралары китерә

торган зыян күләме, Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташыганда, 0 га тигез.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\445.doc